ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

29.10.2025 № 795

**2026 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларының һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы «Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф учреждениеләрен һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елга расларга:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-

фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларында һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарны;

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының өстәмә белем бирү оешмаларында инклюзив белем бирүне оештыру юлы белән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, инвалидлыгы булган укучылар өчен өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарны;

балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга 0,9 күләмендә төзәтмәләр коэффициентын.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә тарала.

4. Карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф.Хәкимуллин

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 29.10.2025 № 795нче___ ___ номерлы карары белән расланды

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларында һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга
НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар, 1 укучыга елга сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | укытуның беренче елы | укытуның икенче елы | укытуның өченче һәм аннан соңгы еллары |
| Сәнгати-эстетик | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 9 441 | 17 142 | 20 490 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 9 941 | 17 642 | 20 990 |
| Туристик-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |
| Экологик-биологик | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |
| Социаль-педагогик һәм икътисадый | авыл җирлеге | 9 341 | 17 042 | 20 390 |
| Табигый-фәнни | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының өстәмә белем бирү оешмаларында инклюзив белем бирүне оештыру юлы белән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, инвалидлыгы булган укучылар өчен өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыруга
НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар, елга сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | терәк-хәрәкәт аппараты бозылулары, психик үсеше тоткарлануы, аутистик спектры бозылулары һәм үсешендә күп төрле авыр бозылулары булган бер укучыга | | | ишетү сәләте бозылган бер укучыга: чукраклар, начар ишетүчеләр, соңрак чукракланганнарга | | |
| | | укытуның беренче елы | укытуның икенче елы | укытуның өченче һәм аннан соңгы еллары | укытуның беренче елы | укытуның икенче елы | укытуның өченче һәм аннан соңгы еллары |
| Сәнгати-эстетик | авыл җирлеге | 19520 | 32068 | 35416 | 13864 | 23719 | 27067 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 19420 | 31968 | 35316 | 13764 | 23619 | 26967 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 19920 | 32468 | 35816 | 14264 | 24119 | 27467 |
| Туристик-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 19520 | 32068 | 35416 | 13864 | 23719 | 27067 |
| Экологик-биологик | авыл җирлеге | 19520 | 32068 | 35416 | 13864 | 23719 | 27067 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 19520 | 32068 | 35416 | 13864 | 23719 | 27067 |
| Социаль-педагогик һәм икътисадый | авыл җирлеге | 19320 | 31868 | 35216 | 13664 | 23519 | 26867 |
| Табигый-фәнни | авыл җирлеге | 19520 | 32068 | 35416 | 13864 | 23719 | 27067 |